Фәттахова, Лилия. Әдәби Чаллы / Лилия Фәттахова // Казансу: альманах: мәкаләләр, шигырьләр, хикәяләр / [төзүчесе һәм кереш сүз авторы Г.Закирова]. – Казан: Татар китап нәшрияты, 2024. – Б. 62-66.



# ӘДӘБИ ЧАЛЛЫ

*Мин Чаллы шәһәренең әдәби мохитенә чагыштырмача күптән түгел — биш ел элек килеп кердем. Шулай да әйтә алам: аралашкан язучы-шагыйрьләрнең күбесе — КамАЗ юлын үткән, «тормышның төбеннән» күтәрелгән, «КамАЗ киңлегенә тиң әсәрләр» иҗат иткән шәхесләр. Сүзем — Чаллы төбәге каләм әһелләре хакында.*

## «Бумерлар»дан «зумерлар»га

Моннан нәкъ кырык ел элек Чаллы шәһәре комитетының беренче секретаре Рәис Беляев болай дип яза: «Хәзер Чаллы Язучылар оешмасында СССР Язучылар союзының тугыз әгъзасы, ике йөздән артык яшь һәм башлап язучы исәпләнә. Филология фәннәре докторы, тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин, язучылар Эдуард Касыймов, Кадыйр Сибгатуллин, Нәҗип Мадьяров, Мәхмүт Газизов, Равил Вәлиев, Рахмай Хисмәтуллин һәм алар белән янәшә торып иҗат итүче Ямаш Игәнәй, Газиз Кашапов, Наип Ләисов, Хәниф Хөснуллин, Рафис Сәлимҗанов, Альберт Сафин кебек яшь талант ияләре КамАЗ елъязмасына үзләренең лаеклы өлешләрен керттеләр.

Язучылар оешмасы көннән-көн ныгый бара, хәзер инде ул шәһәр күләмендә үткәрелгән бер генә зур чарадан да, бер генә олы вакыйгадан да читтә калмый. Моңа кадәр эшләгән эшләренә югары бәя биргән хәлдә, без язучылардан һәм культура фронты хезмәткәрләреннән әле КамАЗ киңлегенә тиң әсәрләр, КамАЗ төзүчеләре һәм эшчеләре хезмәтенә тәңгәл килерлек ялкынлану, илһамлану көтәбез».

Мин Чаллы шәһәренең әдәби мохитенә чагыштырмача күптән түгел — дүрт ел элек килеп кердем. Шулай да әйтә алам: аралашкан язучы-шагыйрьләрнең күбесе — КамАЗ юлын үткән, «тормышның төбеннән» күтәрелгән, «КамАЗ киңлегенә тиң әсәрләр» иҗат иткән шәхесләр. Факил Сафин, Сирень Якупова, Рәшит Бәшәр, Әлфия Ситдыйкова, Айрат Суфиянов, Марс Яһудин…

Алар, — Штраус—Хау теориясе буенча, «бумерлар» буыны. Монда әле иҗтимагый институтлар көчле, индивидуальлек йомшак чагыла. Бу чорда кешеләрне үзара җанлы аралашу, бәйрәмнәр, кичәләр якынайта. Чаллы гөрли! Мин — шуннан соңгы «Х» буыны вәкиле, элеккеге системаның таркалуын, яңасының урнашуын, үзебезчә әйтсәк, дөньяның асты өскә килүен күргән кешеләрнең берсе; социалистик реализм белән язасы каләм иясе түгел, күңелдәге ризасызлык-канәгатьсезлек шигырьләргә дә үтеп керә… Ләкин мин инде үземнән соңгыларны — «миллениал» белән «зумерлар»ны тулаем аңлый алмаячагымны да беләм. Алар — индивидуалистлар, алар тере аралашуга караганда Интернет аша аралашуга өстенлек бирә, алар социаль челтәрләрдә «яши». Элеккеге буыннар белән чагыштырганда стресска һәм депрессиягә ешрак бирелүчән, үзгәрешләрдән курыкмыйлар…

Әлеге бүленешне хикәяләре матбугатта күренгәләп торган яшь каләм иясе Рузанна Каюмова (25 яшь) искә төшерде (минем өчен ул бер теория сыманрак кына иде), баксаң, зумерларның (ул үзен шулай атады) уй-сөрешләре чынлап та башкача икән бит. Аның чиле-пешле әсәрен дөньяга чыгарасы килми, аңа офлайн очрашулар бик кирәк түгел (гәрчә күңел ачу өчен яшьләргә андый очрашулар кирәклеген дә инкяр итми), язганнарын социаль челтәрдә тәкъдим итү аңа публика каршында чыгыш ясауга караганда җиңелрәк тә, канәгатьлекне дә күбрәк бирә.

Безгә, татарча язучы яшьләрнең булуын һәм күбрәк булуын теләгән каләм әһелләренә, сабак булырлык сүзләр дә әйтте Рузанна: «Кушып, ашыктырып яздырган һәм тәҗрибәлерәк язучылар тарафыннан «җиңеләйтелгән» бер хикәямнән соң ел ярым бөтенләй берни дә яза алмадым. Сезнең барыгызга да яшь язучы кирәк булуын аңлыйм, шылтыраткалап торалар, тик үз күңелемдә «пешеп бетмәгән»не матбугатка бирәсе килми, шуңа күрә ашыкмаска булдым». Ә остазлардан ярдәмнең рус телендәге «Курсы писательского мастерства» рәвешендә онлайн форматта булуын тели ул. Мәсәлән, тәҗрибәле язучы-кураторлар бирәр тема бирсә, шул темага язылган әсәрләрне порталга урнаштырып, фикерләр язарга, язу техникалары белән бүлешергә булыр иде, ди.

***«Зумерлар»ның чиле-пешле әсәрләрне дөньяга чыгарасы килми, аларга офлайн очрашулар кирәк түгел, язганнарын социаль челтәрдә тәкъдим итү рәхәтрәк.***

## Стереотиплардан качу һәм миллилеккә ихтыяҗ

«Татарча сөйләшүче яшьләрне күрү белән, сездә бөтен өмет, диләр», – ди Чаллы яшьләренең URBANTATAR берләшмәсе җитәкчесе Гүзәл Әхмәтгәрәй. Иҗатка ирекне кысу, карашларны тарайту кебегрәк ишетелә аңа бу сүзләр. Ник дигәндә, шул сүзләрдән соң «сез шулай эшләргә тиеш, шундый булырга тиеш...» кебегрәк нәсыйхәт-йөк өелә. «Тиеш, кирәк!» дигән өндәү-сүзләр һәркемнең күңеленә аңлы рәвештә үтеп керсә генә нәтиҗәле ул. «Ярат!» дип кенә яраттырып булмаган шикелле.

Шамил Идиятуллинның «Город Брежнев» романы буенча «Шәһәр. Нокта. Брежнев» спектакле Гүзәлнең тәрҗемәдәге беренче дебюты дип тә беләм. Ике ел рәттән үткәрелгән «Әдәби лаборатория» кебек кызыклы эксперимент та — аның башлангычы. Беренче тапкыр әдәби иҗатка «чумып» алган төрле өлкәләрдә эшләүче яшьләр өчен үзенә күрә бер чакыру – «Һәркем хикәя яза аламы?» дигән сорауга җавап эзләү, үз-үзләрен сынап карау булган ул.

Гүзәлнең үзен дә читтән караганда актив иҗат итә дип әйтеп булмый. Якыннан аралашканда гына, аның язганнарын укучы даирә бар икәнлеген беләсең. Ул да зур аудиториягә, матбугат битләренә чыгарга ашыгып тормый. Классик әдәбиятка бераз скептикларча карыйм, ясалмалылыктан

куркам, ди Гүзәл. Чишелеш, төенләнеш, идея-проблема, ягъни «әдәбият шундый булырга тиеш» дигән кысалар язарга комачаулый кебек тоела аңа. Үзенә күбрәк нон-фикшн стиле якын – XXI гасыр чынбарлыгында үз кичерешләрен язып бара. Социаль челтәрләрен ике телдә дә алып бара, әдәби сүзне исә татарча гына язам, ди шәһәр кызы Гүзәл. Уйларга, фикер йөртергә өйрәткән өчен, әдәбият укытучысына һәм Альберт Яхин укыту системасына рәхмәтле (Сингапур методикасы дип зурдан купканчы, үзебезнең яхшы өлгеләрне файдаланасы иде шул, килешәм).

«Әгәр Чаллыда калсам, берәр каһвәханә ачар идем. Анда татарча винил пластинкалар әйләндерер идем, иң шәп татар китаплары белән тулган стеллаж торыр иде. «Куда можно будет прийти и почувствовать «ламповость» быть татарином». Гүзәлнең социаль челтәрдәге сәхифәсендә бер посттан өзек бу. Менә шулай! Яшел лампа яктысы астында җылы дустанә мохит. Милли мохитне сорый торган күңел. Стереотиплардан качу һәм миллилеккә ихтыяҗ.

Чаллыда шундый яшьләр бар. Һәм алар әдәби кысаларга керергә атлыгып тормый. Әллә шуңамы, «Чаллының яшь каләм ияләре» дигәндә, өлкәнрәкләр алар турында белми дә диярлек. Ләкин алар бар. Һәм алар миңа XIX гасырның «разночинец»ларын хәтерләтә: үз кулларыннан килгәнне, үз күңелләре кушканны эшлиләр, «кече эшләр территориясе»н булдыралар. Болындагы кырмыска оясын да янына килеп җиткәч кенә күрергә мөмкин бит, аңа карап кына, ул кырмыскалар юк дигән сүз түгел әле.

## *Остазлар мәктәбен узу кирәкме?*

Чаллының әдәби тормышы моннан кырык еллар элек Кадыйр Сибгатуллиннар, Мөдәррис Әгъләмовлар, Разил Вәлиевләр чагындагы кебек түгел, әлбәттә. Безнең тулаем әдәбиятыбыз да ул чактагы кебек түгел – Мөхәммәт Мәһдиевләр, Аяз Гыйләҗевләр, Туфаннар чоры узды – кыйммәтләр алышынды, глобальләшү процессы көчәя төште, телебезнең, әдәбиятыбызның уку йортларындагы урыны мөшкелләнде. Хәзер инде Чаллыда татар филологиясе бүлеге юк, димәк, заманында гөрләп торган иҗади түгәрәкләр дә юк дигән сүз бу. Димәк, остазлар мәктәбен узу, әдәби чирканчык алу мөмкинлеге булган бер үзәккә саекты милли мохит. Ә бит кайбер яшьләргә кирәк ул. Соңгы елларда шигырь, хикәяләре матбугатта күренә башлаган Айзирә Имамова, мәсәлән, Чаллы язучылары белән танышуын бәхет дип саный: «Һәркайсы ярдәмчел, киңәш бирергә әзер. Факил Сафин, Әлфия Ситдыйкова, Лилия Гыйбадуллина кирәк чакта фикер-киңәшләрен әйтә. Әле минем канат нытыткан чак. Кайчан да булса алар кебек биектә очармын дип өмет итәм».

Язучылар берлегенең Чаллы бүлегендә иллеләп язучы бар. Безнең бүлеккә Алабуга, Актаныш, Түбән Кама, Мамадыш һ. б., ягъни Кама аръягы шәһәр һәм авыллары каләм ияләре керә. Без үзебезнең Фоат Садриев, Фәүзия Бәйрәмова, Айдар Хәлим, Факил Сафин, Айгөл Әхмәтгалиева кебек әдипләребез белән горурланабыз. Безнең арада талантлы



*Чаллының бүгенге иҗатчы егет-кызлары*

шагыйрә Лилия Гыйбадуллина иҗат итә. Һәм үзара дустанә, ихтирамлы мөгамәлә бездә. Миңа шулай тоела. Күптән түгел «Мәйдан»ның Ютуб каналында һәм социаль челтәрләрдә Чаллы әдипләре белән таныштыра башладык: безнекеләр Интернет мәйданында да яңгырарга тиеш!

Алинә Хәбибуллина, Сәрбиназ Шәйхелова, Гөлназ Нуриева, Алсу Сәлахова... «Көмеш кыңгырау» газетасында, хәзер инде «Мәйдан» журналында эшләгәндә, әдәби иҗатка тартылган яшьләр арасында үзебезнең төбәктән чыгучыларның, бигрәк тә актанышлыларның, күплеген күрәм. Чагыштырмача, әлбәттә. Тик аларның күбесен Казан үзенә тарта. Без аларның уңышларына читтән генә сөенәбез һәм... мәктәпләргә, очрашуларга чыкканда, каләмгә тартылган башка балаларны, башка студентларны күрергә, табарга тырышабыз. Журналыбызда «Дуслар-ча шәрех» дигән сәхифә дә булдырдык: анда яшь иҗатчыларга редакция хезмәткәрләре — Лилия Гыйбадуллина, Айрат Суфиянов һәм мин фәкыйрегез — киңәш-теләкләребезне җиткерәбез. Чаллының 84 нче лицей укучысы Данил Сәйфуллин, Әлмәт кызы Сәрбиназ Шәйхелова, Алабуга институты студенты Алёна Евдокимованың иҗатлары тәкъдим ителде инде.

## «Ләйсән»нең үз дөньясы

Чаллыда иҗатчылар өчен тагын бер үзәк — «Ләйсән» әдәби берләшмәсе бар. Бүгенге көндә зур танылу алган никадәр язучы заманында әлеге берләшмәгә йөргән! Аларны санап китү генә дә күп урынны алыр иде.

Берләшмәгә бүгенге көндә утызлап кеше йөри. Социаль челтәрләр аша үз укучыларын булдырган Рәзиф Дәүләт-Бикбаулы, Рәзинә Сәетгәрәева,

Айрат Шәйхетдиновны аерып әйтергә кирәктер. Зифа Кадыйрова исә популярлыгы ягыннан күп кенә исемле язучылардан да алдарак тора.

Берләшмәнең җитәкчесе Роза Хәмидуллина ике тапкыр «Әдәби Чаллы» антологиясен төзеп чыгарды, анда Чаллының әдәби дөньясына үз өлешен керткән йөзләгән каләм иясенең әсәрләре урын алган.

«Ләйсән»леләр Чаллы бүлегенә карый һәм үзара тыгыз элемтәдә тора. Бер генә тамчы дегет – берләшмәгә урта һәм олы буын вәкилләре йөри, яшьләр үз дөньяларында, үз стихияләрендә. Һәм бу шулай булырга тиештер дә. (Юкка гына, Казанда да яшьләрнең үз оешмалары булырга тиеш, дип йөрделәрмени?!)

«Ләйсән» әдәби берләшмәсе шәһәрнең Муса Җәлил исемендәге Үзәк китапханәсендә урнашкан. Язучылар бүлегенең үз «фатиры» булганчы, йөзләгән кичә, очрашулар узды монда. Очрашулар дигәннән, мәктәпләрдә дә, китапханәләрдә дә еш булабыз без. Бүгенге көндә китап сүзен, әдәби сүзне җиткерүнең бу форсатын ычкындыру һич тә дөрес булмас иде.

Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил абый Сафин тырышлыгы белән зурлап Әдәбият көннәре, Илдар Юзеев премиясен тапшыру тантанасы үткәрелә. Соңгы айлардагы вазгыять кенә бераз чикләүләр кертте.

## Яшь язучыларның да күбесе утыздан өстә

Шулай да язучыларыбызның бик күбесе өлкән буын вәкилләре инде. Иң яшь иҗатчыларыбыз да утыздан өстә (Лилия Гыйбадуллина, Фидаил Мәҗитов). Әгәр «зумерлар» буыны вәкилләренең берничәсен булса да белмәсәм, «хәлләр хөрти» дияр идем. Ә Сирень Якупованың шигырьләренә «Чатта» дип аталган перформансны күргәч (сценарий авторы – Айгөл Әхмәтгалиева, режиссёры – Гүзәл Әхмәтгәрәй) һәм Чаллы яшьләре @modern.tatar төркеменең шигъри сүзне йөрәкләргә үтәрлек итеп җиткерүен ишеткәч, Аллага шөкер икән әле, дим. Лилия Гыйбадуллинаның иҗатын колачлаган яңа форматтагы кичә әзерләнә менә. Дары савытында дары бетмәгән әле.

Куандырган тагын бер яңалык – Чаллы бүлеге язучыларының даими җыелу урыны булдырылды. Аның Аяз Гыйләҗев исемендәге драма театрында урнашуы да, театр бинасында иҗади яшьләр өчен коворкинг – хезмәттәшлек мәйданчыклары булуы да хуп. Театрның әдәби бүлек мөдире булып Айгөл Әхмәтгалиеваның эшләве дә һәртөрле башлангычларга, әдәби багланышларның артуына зур ышаныч тудыра.

Кыскасы, @modern.tatar төркеме яшьләрендә «Милләт бетә» дигән язулы футболкаларны беренче күргәндәге сискәнү узды инде миндә. Хәер, нәкъ шулай сискәндерү өчен эшләнә дә инде яшьләрнең ул милли проектлары. Иң мөһиме – алар булсын. Милли контент күбрәк булган саен, киләчәктә дә әдәбият-сәнгатебез сакланыр дигән өмет уяна. Ләкин ул инде без кабул итеп гадәтләнгәнчә – түбәтәйле-калфаклы, читек-кәвешле түгел, башкачарак, заманчарак, миллениал-зумерлар теләгәнчәрәк булыр.

***Лилия ФӘТТАХОВА***